**СОВЕТ**
**АКБУРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. Октябрьская, д. 44,**
**с. Акбуре, 423197**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АКБҮРЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**Октябрь урамы,44 нче йорт**
**Акбүре авылы, 423197**

тел.: (8-84348) 3-62-40, факс: (8-84348)3-62-40, Akbur.Nsm@tatar.ru

КАРАР

2019 елның 11 ноябере № 1

"Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбүре авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Акбүре авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акбүре авыл җирлеге башлыгы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбүре авыл җирлегенең Сөлчә Баш авылы Урманлы урамында яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 7 нче декабрь көнне сәгать 10.00 сәгатькә Сөлчә Баш авылында Урманлы урамы, 8 нче йортта урнашкан авыл клубында уздырырга дип билгеләргә.
2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбүре авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2020 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбүре авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге бүлектә укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, 1 нче группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның ялгыз калган тормыш иптәшләре, балачактан мөмкинлекләре чикле булган гражданнардан тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

-су башнясы (су алу скважинасы) территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү (материаллар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

“РИЗА” "КАРШЫ"

4. Әлеге карарны «Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акбүре авыл җирлеге башлыгы Җ.М.Җәләлетдинов